**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
11.03.2020

КАРАР
№ ПР-43

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 3 августындагы 400 номерлы карарын үтәү йөзеннән, балаларны йөртү өчен файдаланыла торган автобусларда йөртүнең иминлеген тәэмин итү максатларында, **карар бирәм:**

1. Мәктәп автобус маршрутларын тикшерү актлары нигезендә, 2020 елның 9 гыйнварыннан түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:

1.1. 17 нче номерлы «Теләкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе " муниципальара махсус автобус маршруты;

1.2. 18 нче номерлы «Чуракай-Байсар төп гомуми белем бирү мәктәбе " муниципальара махсус мәктәп маршруты;

2. "Татавтодор" АҖ Минзәлә филиалының Актаныш ДРСУ башлыгына тәкъдим итәргә:

- автомобиль юлларын, юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

3. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- автомобиль юлларын, юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

4. "Актаныш АТХ" МУП директорына тәкъдим итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ белән килештерелгән автобус маршрутлары паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте расписаниесен эшләргә һәм раслауга тапшырырга;

- мәктәп маршрутларын тикшерү буенча рәсмиләштерелгән актларны Башкарма комитет житәкчесенә тикшерү тәмамланганнан соң биш көн эчендә тапшырырга;

- расланган расписание нигезендә мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне катгый тәэмин итү;

-3 елдан да ким булмаган өзлексез эш стажына ия булган машина йөртүчеләрне мәҗбүри инструктаж уздыру белән тәэмин итәргә;

- мәктәп автобусларын эксплуатацияләү өчен җаваплы башкаручыларны билгеләү буенча боерык чыгарырга.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән маршрутлар буенча мәктәптә йөртүнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катгый контроль оештырырга.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- балаларны торак пунктлардан база мәктәбенә кадәр һәм кире кайтарган өчен, балаларның исемлеген мәҗбүри күрсәтеп, җаваплы укытучыларны (озатып йөрүче) билгеләргә. Ай саен озатып йөрүче укытучылар һәм укучылар белән мәҗбүри инструктажлар үткәрергә.

7. Әлеге карар веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында - http://aktanysh.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев